| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>Совет<br>Афанасовского сельского поселения<br>Нижнекамского муниципального района<br><br>423551, Нижнекамский район,<br>с. Большое Афанасово ул. Молодежная,1 | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>Түбән Кама муниципаль районы<br>Афанас авыл жирлеге<br>Советы<br><br>423551, Түбән Кама районы,<br>Олы Афанас авылы, Яшьләр урамы, 1 |
|---|---|

тел./факс (8555) 44-43-39, электронный адрес: Afanasovskoe.sp@tatar.ru,
сайт: www.afanasovskoe-sp.ru


РЕШЕНИЕ КАРАР

10.11.2023 ел № 09-17

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Афанас авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2018 елның 23 июлендәге 08-17 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлегенә ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Афанас авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Афанас авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Афанас авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2018 елның 23 июлендәге 08-17 номерлы карарына (алга таба - Карар) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

Карарның 2 пунктындагы 1 пунктчасының өченче абзацында «бирелгән» һәм «, дача» сүзләрен төшереп калдырырга;

Карарның 3.1 пунктның алтынчы абзацында «мәйданы 30 квадрат метрдан артмаган» сүзләрен төшереп калдырырга;

Карарның 3.1 пунктындагы җиденче абзацын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә игълан итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

СОВЕТ АФАНАСОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ОГРН 1021602512800 ИНН 1630003098

Д.А. Филиппов